КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 август г.Казань № 728

2020 елга өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2020 елга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә урнашкан медицина оешмалары каршындагы сөт өләшү пунктлары һәм яхшы сыйфатлы туклану пунктлары аша өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны;

2020 елга «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшенең күләмен.

2. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына, «Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесе белән берлектә, туклану өчен махсус һәм сөт продуктларын алучы өч яшькә кадәрге балаларны балаларның категорияләре, яшьләре һәм алына торган продукция төрләре буенча аерым исәпкә алуны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус һәм сөт продуктлары белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2018 ел, 4 сентябрь, 752 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

4. Бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Премьер-министр
Республики Татарстан А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 28 август, 728 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә урнашкан медицина оешмалары каршындагы сөт өләшү пунктлары һәм яхшы сыйфатлы туклану пунктлары аша өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнар

| Балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары алучылар категориясе | Түбәндәге яшьтәге балаларга норматив чыгымнар, 1 көнгә сум | | |
|---|---|---|---|
| | 0 айдан 6 айга кадәр | 6 айдан 1 яшькә кадәр | 1 яшьтән 3 яшькә кадәр |
| «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законына кушымтада билгеләнгән җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнә торган яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган гаиләләрдә яшәүче өч яшькә кадәрге балалар;<br>балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән түләүсез тәэмин итү рәвешендә социаль ярдәм чарасы күрсәтелә торган авырулар исемлегенә керүче авырулары булган өч яшькә кадәрге балалар | 21,82 | 45,62 | 31,71 |
| ВИЧ-инфекцияле авыру аналардан туган балалар һәм ВИЧ-инфекция белән авыручы балалар | 87,28 | - | - |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 28 август, 728 нче
карары белән расланды

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшенең күләме

| Балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары алучылар категориясе | Балаларның яше | Бер елга дәүләт эше күләме, бала-көн | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | адаптация-ләнгән сыек сөт кат-нашмасы | сөт | кефир | эремчек |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законына кушымтада билгеләнгән җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнә торган яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган гаиләләрдә яшәүче өч яшькә кадәрге балалар; балалар туклануы өчен махсус һәм сөт продуктлары белән түләүсез | 0 айдан 6 айга кадәр | 882 060 | - | - | - |
| | 6 айдан 1 яшькә кадәр | 3 078 060 | 3 078 060 | 3 078 060 | 3 078 060 |
| | 1 яшьтән 3 яшькә кадәр | - | 10 968 288 | 10 968 288 | 10 968 288 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| тәэмин итү рәвешендә социаль ярдәм чарасы күрсәтелә торган авырулар исемлегенә керүче авырулары булган өч яшькә кадәрге балалар | | | | | |
| ВИЧ-инфекцияле авыру аналардан туган балалар һәм ВИЧ-инфекция белән авыручы балалар | 0 айдан 6 айга кадәр | 24 522 | - | - | - |

---